СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2020 г.Лениногорск № 30

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә торак исәбендә торучы гражданнарга муниципаль торак фонды турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 24 номерлы Лениногорск муниципаль район Советы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә торак исәбендә торучы гражданнарга торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

РФ Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 14 июнендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә торак исәбендә торучы гражданнарга муниципаль торак фонды турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 24 номерлы Лениногорск муниципаль район Советы карары белән расланган “Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә торак исәбендә торучы гражданнарга торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

13 бүлекнең 6 абзацын

«шулай ук Федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән башка категория гражданнар» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый-мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов